**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» Указына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе эшчәнлеген камилләштерү максатларында **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасы дәүләт органнарында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфаларының гомуми санын раслау турында» 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1214 номерлы, 2013 елның 14 декабрендәге ПУ-1215 номерлы, 2014 елның 20 августындагы ПУ-797 номерлы, 2014 елның 1 октябрендәге ПУ-949 номерлы, 2014 елның 17 ноябрендәге ПУ-1052 номерлы һәм 2015 елның 25 мартындагы ПУ-367 номерлы, 2015 елның 17 июнендәге ПУ-562 номерлы, 2015 елның 26 июнендәге ПУ-602 номерлы, 2015 елның 29 июлендәге ПУ-680 номерлы, 2015 елның 10 сентябрендәге ПУ-850 номерлы, 2015 елның 24 сентябрендәге ПУ-892 номерлы, 2015 елның 17 октябрендәге ПУ-995 номерлы, 2016 елның 6 апрелендәге ПУ-331 номерлы, 2016 елның 19 апрелендәге ПУ-366 номерлы, 2016 елның 31 маендагы ПУ-491 номерлы, 2016 елның 6 декабрендәге ПУ-1075 номерлы, 2016 елның 23 декабрендәге ПУ-1192 номерлы һәм 2016 елның 26 декабрендәге ПУ-1228 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) 1 нче кушымтага, 29 пункттагы «130» санын «134» санына алмаштырып, үзгәреш кертергә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына:

билгеләнгән тәртиптә әлеге Указны гамәлгә ашыру белән бәйле чыгымнарны финанслауны тәэмин итәргә;

үзенең актларын әлеге Указга туры китерергә, шулай ук аны гамәлгә ашыруны тәэмин итүче башка карарлар кабул итәргә.

3. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ГОМУМИ БҮЛЕК / ОБЩИЙ ОТДЕЛ — ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Казан,Кремль
2017 ел, 15 февраль
№ ПУ-143